**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№10902**
**10.11.2023**

2023-2024 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урыннарын билгеләү турында

Карны үз вакытында чыгаруны тәэмин итү һәм кар өюне тәртипкә салу максатларында, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 190 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2023-2024 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урыннарын билгеләргә:

1) кадастр номеры 16:52:100305:351 булган җир участогы территориясендә;

2) кадастр номеры 16:52:000000:5172, мәйданы 10 га булган җир участогы территориясендә;

3) кадастр номеры 16:52:100101:81 булган җир участогы территориясендә.

2. 2023-2024 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урыннарының урнашу схемасын кушымтада каралганча расларга.


3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2023 елның 10 ноябрендәге
10902 номерлы карарына
кушымта

2023-2024 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урыннарының урнашу схемасы




Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева